ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2019 елның 27 ноябре № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлеге Яңа Александровка авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Яңа Александровка авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, (I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар) 500 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру**

Яңа Александровка авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Яңа Александровка авылында кырларны чабу эшләре.

**- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

Яңа Александровка авылында ком һәм вак таш (ЩПС), Энгельс урамы; Карл Маркс урамы буенча;

Яңа Александровка авылының кышкы чорында автомобиль юлларын карап тоту»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы С.С. Елисеев